**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 16 декабрендәге 4458 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2014 елның 3 мартындагы 1221 номерлы**
**«Казан шәһәренең автомобиль юлларында**
**шәһәр пассажир транспорты хәрәкәте өчен**
**полосалар бүлеп бирү турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәренең шәһәр пассажир транспорты хәрәкәте өчен полосалар бүлеп бирелгән урам-юл челтәре участоклары үзгәрүен исәпкә алып, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 3 мартындагы 1221 номерлы «Казан шәһәренең автомобиль юлларында шәһәр пассажир транспорты хәрәкәте өчен полосалар бүлеп бирү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 5 февралендәге 492 номерлы һәм 2025 елның 8 июлендәге 2125 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«1.1. Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә Дементьев урамында, Тэцевская урамыннан Олег Кошевой урамына кадәрге участокта, Максимов урамына, Ленинград урамына таба хәрәкәт итү юнәлешендә, Копылов урамында, Хөсәен Ямашев проспектында, Чистай урамында, Маршал Чуйков урамында, Фатыйх Әмирхан урамында, «Миллениум» күперендә, Ибраһимов проспектында, Декабристлар урамында, Киров дамбасында, Болотников урамында, Восстание урамында, Фрунзе урамында, Горький Шоссесы урамында, Залесная урамында, Несмелов урамында, Кремль дамбасында, Меңьеллык мәйданында, Уң як Болак урамында, Сул як Болак урамында, Татарстан урамында, Пушкин урамында, Татарстан урамыннан Карл Маркс урамына кадәрге участокта, Карл Маркс урамында, Горький урамында, Вишневский

урамында, Николай Ершов урамында, Марсель Сәлимҗанов урамында, Островский урамында, Туфан Миңнуллин урамыннан Пушкин урамына кадәрге участокта, Нурсолтан Назарбаев урамында, Павлюхин урамында, Себер Тракты урамында, Рихард Зорге урамында, Җиңү проспектында, Академик Арбузов урамында, Академик Сахаров урамында, Академик Глушко урамында, Зәкиев урамыннан Хәйдәр Бигичев урамына кадәрге участокта, Достоевский урамында, Гадел Кутуй урамыннан Чехов урамына кадәрге участокта, Гадел Кутуй урамында, Мир урамында, Юлиус Фучик урамында, Оренбург Тракты урамында, Павлюхин урамыннан Ферма Шоссесы урамына кадәрге участокта, Танк урамында, Гвардия урамында, Хөсәен Мәүлүтев урамында, Академик Парин урамында, Альберт Камалиев проспектында, Курск урамыннан Альберт Камалиев проспектындагы 30 номерлы йортка кадәрге участокта, маршрут транспорты чаралары хәрәкәте өчен махсус бүленгән полосалар буенча шәһәр пассажир транспорты хәрәкәтен оештырырга»;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 3 мартындагы 1221 номерлы «Казан шәһәренең автомобиль юлларында шәһәр пассажир транспорты хәрәкәте өчен полосалар бүлеп бирү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә;

2.2. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**